Сәҗдә әс-сәһву

سجود السهو

اللغة التترية

Шәйх Хәйсәм ибн Мөхәммәд
Сәрхән

ALSARHAAN.COM
MAHADSUNNAH.COM

السهو: نسيان الشيء والغفلة عنه.

Әс-сәһвү – үл нәрсәне дә булса онытып калдыру һәм игътибарсызлык.

وسجود السهو : هو سجدتان تكونان آخر الصلاة أو بعدها. لجبر خلل أو ترك واجب من واجبات الصلاة سهوا.

Әс-сәһвү сәҗдәсе– үл кимчелекләрне төзәтер өчен я инде намазда булган үәҗиб нәрсәләрне онытып калдырганлыктан намазның ахырында яки намаздан соң кылына торган ике сәҗдә.

ويستوي في ذلك الفرض والنافلة.

Һәм монда аерма юк: фарыз намазы булсынмы үл яки нәфел намазымы.

وأسباب سجود السهو.

الزيادة والنقص والشك.

Әс-сәһвү сәҗдәсенең сәбәпләре: намазда нидер арттыру (өстәү), киметү яки шикләнү.

أما الزيادة سهوة فمن زاد ركوعا أو سجودا او قعودا ناسيا سجد للسهو بعد السلام.

Өстәүгә килгәндә, кем дә кем онытылып рөкүг яки сәҗдә яки утырып торуны өсти икән, ул сәламнән соң ике сәҗдә кыла (сәҗдә әс-сәһвү).

واما النقصان سهوا فمن ترك ركنا كركوع أو سجود أتى به وأتم صلاته وسجد للسهو بعد السلام.

Киметүгә килгәндә, кем дә кем онытылып намазның рөкүг, сәҗдә шикелле нигезләрен калдыра икән, ул аларны тулылындыра (кайтара) һәм намазын тәмамлагач, сәламнән соң, сәҗдә әс-сәһвү кыла.

ومن ترك واجبا كالتشهد الأول والجلوس له فإنه يواصل صلاته ولا يأتي به.
لكنه يسجد للسهو قبل السلام.

Һәм кем дә кем беренче тәшәһһүд яки анда утыру кебек намазда үәҗиб булган гамәлләрне калдырса, намазын дәвам итә, аларны кайтармый, ләкин сәлам алдыннан сәҗдә әс-сәһвү кыла.

وأما الشك كأن يتردد هل صلى ثلاثا أو أربعة ؟ فإن ترجح له أحد الطرفين بنى على ما ترجح عنده وسجد للسهو بعد السلام.

Шикләнүгә килгәндә, өч рәкәгать яки дүртне үкыдым микән дип икеләнү яки шикләнү ул. Мондый вакытта намаз укучы инануы күбрәк булган төрне сайлый, ягъни нинди рәкәгатьтә булганына инануы күбрәк булса, шикләнүдән ваз кичеп, үзе ныклап ышанган вариантны сайлап намазын тәмамлый да соңыннан сәҗдә әс-сәһвү кыла.

ومن لم يترجح له شيء بنى على اليقين وهو الأقل. فيجعلها ثلاثا ويأتي برابعة. ويسجد للسهو قبل السلام.

Ләкин шикләнүе нык булып, шушы шикләнгән ике вариантның берсенә дә ныклы инануы булмаса, кимрәк булган вариантны сайлап ала. Ягъни өчме, әллә дүртме рәкәгать үкыганын хәтерләми икән, өч рәкәгать үкыдым дигән инануга таянып дүртенче рәкәгатьне үкый һәм сәлам алдыннан сәҗдә әс-сәһвү кыла.

فيكون السجود للسهو قبل السلام إذا ترك واجبا. أو شك ولم يترجح عنده أحد الطرفين.

ويكون السجود للسهو بعد السلام إذا نقص ركنا أو زاد في صلاته أو شك وترجح عنده أحد الطرفين.

Димәк сүҗүд әс-сәһвү сәлам алдыннан һәм сәламнән соң кылына.

Әгәр намазның үәҗиб гамәле калдырылса, яки ике мәсьәләнең берсенә дә күнмәгән шикләнү бүлса, сәждә әс-сәһвү сәлам алдыннан кылына.

Әгәр намазның нигезе калдырылса яки өстәлсә, яки шикләнгәндә ике мәсьәләнең берендә ныклы ышаныч бүлса, бу вакытта сәламнән соң кылына.

ويجوز السجود للسهو قبل السلام أو بعده.

Сәлам алдыннан да сәламнән соң да сәждә әс-сәһвү рөхсәт ителә.

وإذا سهى المصلي عن سجود السهو فانصرف من الصلاة دون سجود فإنه يعود إليه ويؤديه.
إلا اذا طال الفاصل او انتقض وضوءه فيسقط عنه

Һәм әгәр намаз укучы сәҗдә әс-сәһвү кылырга онытып намазыннан чыкса, һәм бу намаздан соң вакыт күп үтмәгән булса, исенә төшү белән бу сәҗдәне кыла.
Әмма намаздан соң шактый вакыт үтсә яки тәһарәте бозылса бу йөк аның өстеннән төшеп сәҗдә әс-сәһвү кылынмый.

وإذا سهى الإمام في صلاته ثم سجد للسهو فعلى المأموم متابعته في السجود. سواء سَها معه أو انفرد الإمام بالسهو.

Һәм әгәр имам намазында ялгышып, шуннан соң сәҗдә әс-сәһвү ясаса, аның артында намаз укучылар да шулай ук сәҗдәгә төшәләр. Һәм монда аерма юк, алар да имам артыннан кабатлап ялгыштылармы, яки имам үзе генә ялгыштымы.

ومن سها خلف الإمام فليس عليه سجود للسهو.

Һәм кем дә кем имам артында намаз укыганда ялгышса, аңа сәҗдә әс-сәһву ясарга кирәкми.

إلا إن كان مسبوقا فيسجد بعد انتهاء صلاته.

Әгәр ул җәмәгать намазына соңга калып, шушы намазында ялгышса, намазын имамнан соң үзе генә тулыландырган очракта намаздан соң сәҗдә әс-сәһву кыла.

وإذا تكرر السهو للمصلي في الصلاة كفته سجدتان.

Әгәр намаз укучы намазында берничә тапкыр ялгышса да, аңа шулай ук бер генә тапкыр сәҗдә әс-сәһву ясау җитә.